**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» мая 2021 с. Тюлячи № 196

Торак урыны мәйданының исәп нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын тормышка ашыру, дәүләт торак программаларын тормышка ашыру максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин